МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.02.2022 г.Казань № 134

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 28 мартында 9002 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.06.2019 № 484, 16.08.2019 № 624, 14.11.2019 № 1023, 18.06.2020 № 436, 27.07.2020 № 536, 24.09.2020 № 669, 18.12.2020 № 876, 02.06.2021 № 388, 20.09.2021 № 670, 15.11.2021 № 837 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының
28.02.2022 № 134
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.1 пунктны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«1.1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – регламент) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.»;

2.1 пунктны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану»;

2.3 – 2.4 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын (алга таба – хосусый программа) төзү яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар гариза биргән көннән башлап биш эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кичекмәстән кабул ителә.

2.4.3. Гражданинга хосусый программа төзү гариза бирелгән көннән алып ун эш көненнән дә ким булмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

Билгеле бер чорга социаль хезмәтләр күрсәтү хосусый программаны төземичә гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында кабул ителгән карар, хосусый программаны төзү көне һәм урыны турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү гариза бирелгән көннән башлап биш эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән (телефон аша, почта адресы яки электрон почта адресы буенча, Республика порталында, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә) гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану, хосусый программа төзү турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында белдерү җибәрелгән мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар күчермәсен, хосусый программа нөсхәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.6. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору каралмаган.»;

2.15 пунктның түбәндәге эчтәлекле 2.15.4 пунктчасын көчен югалткан дип танырга: «2.15.4. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.»;

2.12 пунктның 2.12.2 пунктчасында «дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затлар» сүзләрен «мөрәҗәгать итүчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризаны һәм документлар комплектын кабул итү һәм карау;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү;

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар нигезендә гражданинның социаль хезмәтләргә хосусый ихтыяҗын билгеләү, хосусый программа төзү һәм гражданинга бирү;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

техник хаталарны төзәтү.»;

3.2 пунктның 3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.2. Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында, Бердәм порталда авторизацияләнә;

Республика порталында, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза рәвешен тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасы таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып Республика порталы, Бердәм портал аша электрон рәвештә җибәрелгән гариза һәм документлар тора.»;

3.4 пунктның дүртенче абзацында «дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче» сүзенә алмаштырырга;

3.5 пунктның 3.5.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында кабул ителгән карар, хосусый программаны төзү көне һәм урыны турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (телефон аша, почта адресы яки электрон почта адресы буенча, Республика порталында, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза (мөрәҗәгать) бирелгән көннән алып биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану, хосусый программа төзү турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында белдерү җибәрелгән мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар күчермәсен, хосусый программа нөсхәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану, хосусый программаны төзү көне һәм урыны турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итү; гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар күчермәсен, хосусый программа нөсхәсен тапшыру административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.»;

3.6 пунктта:

3.6.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә

органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) тарафыннан тапшырылган документлар (документларның күчермәләре) һәм (яисә) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган, шул исәптән гаилә составын характерлый торган, гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән граждannар белән туганлык мөнәсәбәтләрен һәм гражданинның яшәеш шартларын характерлый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мөрәҗәгать итүченең социаль хезмәтләргә булган шәхси ихтыяҗын билгели;

мәгълүмат системасында Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече ике нөсхәдә индивидуаль программа проектын әзерли, аның формасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы килешүнең үрнәк формасы турында, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программа формасы турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 874н номерлы боерыгы белән расланган;

хосусый программа проектын ике нөсхәдә кәгазьдә карап тикшерү һәм имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.5 пунктының 3.5.2 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ике нөсхәдә төзелгән, карау һәм имза кую өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрелгән хосусый программа проекты административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.»;

3.6.2 пунктчасында:

пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) ике нөсхәдә хосусый программа проектын карый, имзалый һәм аларны Учреждение (вәкаләтле оешма) белгеченә җибәрә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан имзаланган, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгеченә җибәрелгән хосусый программа административ процедура нәтиҗәсе булып тора.»;

3.6.3 - 3.6.4 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.3. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан имзаланган хосусый программаны алганнан соң Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) хосусый программаның төзелүе һәм аны гаризада күрсәтелгән ысул белән (телефон аша, почта адресы яки электрон почта адресы буенча, Республика порталында, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә) алу кирәклеге турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.6 пунктының 3.6.2 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер

эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) хосусый программаның төзелүе һәм аны алу кирәклеге турында хәбәр итү тора.

3.6.4. Мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил) хосусый программаны алу өчен Учреждениегә килгәч, Учреждение белгече:

мөрәҗәгать итүчене (законлы вәкилне) хосусый программаның эчтәлеге белән таныштыра;

мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил) хосусый программаның ике нөсхәсен дә имзалагач, бер нөсхәсен аңа тапшыра;

хосусый программаның икенче нөсхәсен Министрлыкның территориаль органына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил) килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә бирелгән хосусый программаның бер нөсхәсе, Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән икенче нөсхәсе тора.»;

3.7 пунктның 3.7.1 - 3.7.5 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.1. Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак мөрәҗәгать итүчегә бирелгән, техник хатасы булган документны теркәп, әлеге Регламентка 9 нчы кушымта нигезендәге үрнәк буенча гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил) тарафыннан гариза Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) шәхсән тапшырыла яисә почта аша, электрон документ рәвешендә электрон почта, Бердәм портал аша, КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыны аша бирелә.

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра;

техник хаталарны төзәтү турында гаризаны Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) җибәрә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура күпфункцияле үзәкнең эш регламентында һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

3.7.2. Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече:

гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) карый;

техник хата төзәтү турында гаризаны техник хатаны төзәтү турында гаризаларны теркәү журналында (әлеге Регламентка 10 нчы кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү көне турында тамгалап, язу бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар техник хата төзәтү турында гариза килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында

бирелгән язу тора.

3.7.3. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарны, хосусый программаны үзгәртеп рәсмиләштерү.

Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече:

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында бирелгән карарда техник хата җибәрелгән очракта, гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын яңадан рәсмиләштерә һәм гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарның яңадан рәсмиләштерелгән проектын Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) имзалау өчен җибәрә;

бирелгән хосусый программада техник хата җибәрелгән очракта:

мәгълүмат системасында хосусый программага төзәтмәләр кертә;

хосусый программаны ике нөсхәдә кәгазьдә чыгартып ала;

ике нөсхәдә хосусый программа проектын карап тикшерә һәм имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: карау һәм имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрелгән гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарның үзгәртеп рәсмиләштерелгән проекты, ике нөсхәдә үзгәртеп рәсмиләштерелгән хосусый программа.

3.7.4. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын, ике нөсхәдә хосусый программа проектын карый һәм имзалый һәм аларны Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7.3 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында яңадан рәсмиләштерелгән карар, хосусый программа.

3.7.5. Министрлыкның территориаль органы белгече мөрәҗәгать итүчегә гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар, хосусый программа турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (телефон аша, почта адресы яки электрон почта адресы буенча, Республика порталында, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар, хосусый программа хакында мөрәҗәгать итүче хәбәр итү.»;

5 бүлекнең 5.2 пунктының 1 пунктчасында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән гариза» сүзләрен өстәргә;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт
күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагында булган, Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарны балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану вәкаләтләре бирелгән оешмалар исемлеге

| № | Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмасының аталышы | Территориясендә (территорияләрендә) гражданнарны балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең (берәмлекләренең) атамасы |
|---|---|---|
| 1 | «Әгерҗе муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр өчен «Ласка» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Әгерҗе муниципаль районы |
| 2 | «Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Забота» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Алексеевск муниципаль районы,<br>Әлки муниципаль районы,<br>Чистай муниципаль районы,<br>Спас муниципаль районы |
| 3 | «Аксубай муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр өчен «Мечта» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Аксубай муниципаль районы,<br>Нурлат муниципаль районы,<br>Яңа Чишмә муниципаль районы,<br>Чирмешән муниципаль районы |
| 4 | «Баулы муниципаль районында | Баулы муниципаль районы, |

| | | |
|---|---|---|
| | балалар һәм яшүсмерләр өчен «Семья» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Ютазы муниципаль районы |
| 5 | «Бөгелмә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Ялкын» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Бөгелмә муниципаль районы,<br>Азнакай муниципаль районы,<br>Әлмәт муниципаль районы,<br>Лениногорск муниципаль районы |
| 6 | «Чүпрәле муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Теплый дом» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Чүпрәле муниципаль районында,<br>Буинский муниципаль районы,<br>Тетюшский муниципаль районы |
| 7 | «Зеленодольск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Гнездышко» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Яшел Үзән муниципаль районы,<br>Апас муниципаль районы,<br>Кама Тамагы муниципаль районы,<br>Кайбыч муниципаль районы,<br>«Казан шәһәре» шәһәр округы,<br>Югары Ослан муниципаль районы,<br>Биектау муниципаль районы |
| 8 | «Мамадыш муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Надежда» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Мамадыш муниципаль районы,<br>Кукмора муниципаль районы,<br>Алабуга муниципаль районы,<br>Балык Бистәсе муниципаль районы |
| 9 | «Менделеевск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Камские зори» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Менделеевск муниципаль районы |
| 10 | «Минзәлә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Минзәлә муниципаль районы,<br>Актаныш муниципаль районы,<br>Мөслим муниципаль районы,<br>Сарман муниципаль районы |
| 11 | «Питрәч муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Шатлык» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Питрәч муниципаль районы,<br>Әтнә муниципаль районы,<br>Арча муниципаль районы,<br>Лаиш муниципаль районы |
| 12 | «Саба муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Саба муниципаль районы,<br>Балтач муниципаль районы,<br>Теләче муниципаль районы,<br>Кукмара муниципаль районы |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | «Түбән Кама муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Балкыш» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | Түбән Кама муниципаль районы, Зәй муниципаль районы |
| 14 | «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Асылташ» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе Яр Чаллы | Яр Чаллы шәһәр округы, Тукай муниципаль районы |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагында булган, Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарны билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану вәкаләтләре бирелгән оешмалар исемлеге

| № | Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмасының аталышы | Территориясендә (территорияләрендә) гражданнарны билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең (берәмлекләренең) атамасы |
|---|---|---|
| 1 | «Казан шәһәре» шәһәр округында ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Милосердие» социаль яраклаштыру үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе җитәкчесе | «Казан шәһәре» шәһәр округы,<br>Югары Ослан муниципаль районы,<br>Лаиш муниципаль районы,<br>Питрәч муниципаль районы,<br>Яшел Үзән муниципаль районы,<br>Әтнә муниципаль районы,<br>Биектау муниципаль районы,<br>Апас муниципаль районы,<br>Буа муниципаль районы,<br>Чүпрәле муниципаль районы,<br>Кайбич муниципаль районы,<br>Кама Тамагы муниципаль районы,<br>Тетюшский муниципаль районы,<br>Арча муниципаль районы,<br>Балтач муниципаль районы, |

| | | |
|---|---|---|
| | | Саба муниципаль районы,<br>Теләче муниципаль районы,<br>Кукмара муниципаль районы,<br>Балык Бистәсе муниципаль районы,<br>Мамадыш муниципаль районы,<br>Алексеевск муниципаль районы,<br>Әлки муниципаль районы,<br>Спас муниципаль районы,<br>Чистай районы,<br>Нурлат муниципаль районы |
| 2 | «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округында ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Перекресток» социаль яраклаштыру үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе җитәкчесе | «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округы,<br>Аксубай муниципаль районы,<br>Яңа Чишмә муниципаль районы,<br>Әгерҗе муниципаль районы,<br>Менделеевс муниципаль районы,<br>Алабуга муниципаль районы,<br>Зәй муниципаль районы,<br>Түбән Кама муниципаль районы,<br>Мөслим муниципаль районы,<br>Актаныш муниципаль районы,<br>Минзәлә муниципаль районы,<br>Тукай муниципаль районы,<br>Бөгелмә муниципаль районы,<br>Азнакай муниципаль районы,<br>Әлмәт муниципаль районы,<br>Чирмешән муниципаль районы,<br>Лениногорск муниципаль районы,<br>Баулы муниципаль районы,<br>Ютаза муниципаль районы,<br>Сарман муниципаль районы»; |

Регламентка 2 нче кушымтада «Гражданинны өйдә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге» таблицасының «Документлар исемлеге» графасындагы 2 пунктта «гражданин» сүзе алдыннан «чит кешеләр каравына мохтаҗ» сүзләрен өстәргә;

Регламентка 3 нче кушымтада «Гражданинны стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге» таблицасының «Документлар исемлеге» графасындагы 6 пунктта «гражданин» сүзе алдыннан «чит кешеләр каравына мохтаҗ» сүзләрен өстәргә;

Регламентка 4 нче кушымтада «Гражданинны ярымстационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге» таблицасының «Документлар исемлеге» графасындагы 2 пунктта «гражданин» сүзе алдыннан

«чит кешеләр каравына мохтаҗ» сүзләрен өстәргә;

Регламентка 6 нчы кушымтада «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка органнар карамагында булган һәм аларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга хокуклы документлар исемлеге» таблицасының 7 пунктында «Документлар исемлеге» графасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә мөрәҗәгать итүченең тору урыны буенча теркәлүен раслый торган белешмәләр»;

Регламентка 7 нче кушымтада «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын (ИППСУ) төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризаларны теркәүгә алу журналы» таблицасында:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналы»;

3 графада «дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче» сүзләренә алмаштырырга;

6 графада «дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 8 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт
күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
8 нче кушымта

Үрнәк

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар
№________ көне _____________

Түбәндәге тарафыннан тапшырылган гариза һәм документлар нигезендә
гр. ___________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
кая___________________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы карары белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибе нигезендә
гр.___________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

гражданинны түбәндәге рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтергә: ____________________________________

(социаль хезмәт күрсәтү формасын күрсәтергә)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ____________________________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесе (Вәкаләтле оешма директоры)

______________ ________________________

(имза) (тулы имза)

Социаль хезмәтләр күрсәтү программасын (алга таба – хосусый программа) төзүдә __________________________ адресы буенча ______ (дата)

(вәкаләтле оешманың адресы)

катнашырга хокуклы.

Хосусый программаны алу өчен__________________________________

(учреждениенең, вәкаләтле оешманың исеме)

____________________ ____________________________________________

(хосусый программаны бирү көне) (учреждениенең, вәкаләтле оешманың адресы)

адресы буенча килергә кирәк.

Мөһер урыны

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану» дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында ____________№______ карар

Гр. ____________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

кая ____________________________________________________________

(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

тапшырган гариза һәм документлар нигезендә, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы карары белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибе нигезендә гр.____________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

Гражданинны түбәндәге рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга:

____________________________________________________________

(социаль хезмәт күрсәтү формасын күрсәтергә)

Түбәндәге нигезләр буенча:

____________________________________________________________

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

______________________________________________________________

(хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Сез, күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәннән соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бу баш тартуга шикаять җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

______________________________________________________________

(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ______________________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесе (Вәкаләтле оешма директоры)

________________ ______________________
(имза) (тулы имза)

Мөһер урыны

Документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

Гр. ________________________________________________тарафыннан
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
кая ______________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)
тапшырылган гариза һәм документлар нигезендә, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы карары белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибе нигезендә гр. ______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)
хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартырга, әлеге нигезләр буенча:

______________________________________________________________

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

______________________________________________________________

(документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Сез, күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәннән соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бу баш тартуга шикаять җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин

______________________________________________________________

(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ______________________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесе (Вәкаләтле оешма директоры)

________________________ ______________________________

(имза) (тулы имза)

Мөһер урыны»;

Регламентка 10 нчы кушымтаның «Техник хатаны төзәтү турында гаризаларны теркәү журналы» таблицасының 4 нче графасында «дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка белешмәлек кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына белешмәлек кушымта

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы булган органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

**1.Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурслар үзәге**

| Вазифа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Директор | (843) 522-87-71 | rrc.kzn@tatar.ru |

**2. Татарстан Республикасы балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар**

| Вазифа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| «Әгерҗе муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр өчен «Ласка» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-85551) 2-52-79 3-93-11 3-92-00 | Spdp.Laska-agreez@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Аксубай муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр өчен «Мечта» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-84344)<br>2-81-31<br>2-81-30 | Spdp.Mechta-aksubaev@tatar.ru |
| «Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Забота» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-84341)<br>2-58-75<br>2-33-83 | Spdp.Zabota-alekseev@tatar.ru |
| «Баулы муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Семья» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-85569)<br>5-14-31<br>5-15-76<br>5-52-56 | Spdp.Semya-bavly@tatar.ru |
| «Бөгелмә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Ялкын» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-85594)<br>9-72-49<br>9-72-65 | Spdp.Yalkyn-bugulma@tatar.ru |
| «Чүпрәле муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Теплый дом» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-84375)<br>3-55-48<br>3-55-16 | Spdp.Teplyydom-drozh@tatar.ru |
| «Зеленодольск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Гнездышко» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-84371)<br>3-41-22<br>3-09-99 | Spdp.Gnezdyshko-zel@tatar.ru |
| «Мамадыш муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Надежда» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-85563)<br>3-29-80<br>3-16-48<br>3-37-24 | Spdp.Nadezhda-m@tatar.ru |
| «Менделеевск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Камские зори» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-85549)<br>2-37-11 | Spdp.Kamskiyzori@tatar.ru |
| «Минзәлә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» дәүләт | (8-85555)<br>2-94-01 | Spdp.Turgay-menz@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| казна учреждениесе җитәкчесе | | |
| «Питрәч муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Шатлык» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-84367)<br>3-24-34<br>3-24-35 | Spdp.Shatlyk-pitrias@tatar.ru |
| «Саба муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-84362)<br>4-16-07<br>4-18-10 | Spdp.Turgay-saby@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Асылташ» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе Яр Чаллы | (8-8552)<br>51-91-90<br>51-91-69<br>51-98-51<br>58-33-89 | Spdp.Asyltash-chelny@tatar.ru |
| «Түбән Кама муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Балкыш» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе | (8-8555)<br>42-83-83<br>36-66-63<br>41-27-86<br>42-93-85 | Spdp.Balkysh-nizh@tatar.ru |

**3. Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыле булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәге**

| | | |
|---|---|---|
| «Казан шәһәре» шәһәр округында ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Милосердие» социаль яраклаштыру үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе җитәкчесе | (843)<br>571-78-47<br>571-78-67 | Tssa.Miloserdiye-kzn@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округында ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Перекресток» социаль | (8-8552)<br>34-06-80,<br>34-99-46 | Tssa.Perekrestok-ch@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| яраклаштыру үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе җитәкчесе | | |

**4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнары яисә шәһәр округлары социаль яклау идарәләре (бүлекләре)**

| Вазифа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85551) 2-10-86 2-11-53 | Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85592) 7-25-10 7-14-25 | Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84344) 2-92-72 2-92-74 | Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85552) 3-11-46 3-12-81 | Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84341) 2-41-40 2-46-46 | Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84346) 2-08-90 2-08-80 | Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районы социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8553) 32-45-50 43-82-15 | Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84376) 2-12-84 2-10-81 | Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84366) 3-13-53 3-13-33 | Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84369) 2-16-60 2-10-84 | Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85569) 5-10-50 5-66-81 5-66-78 5-66-68 | Usz.Bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84368) 2-44-78 2-42-09 2-50-57 2-40-60 | Usz.Baltasi@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Бөгелмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85594) 6-50-44 6-55-70 | Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84374) 3-32-10 3-55-29 | Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84379) 2-17-57<br>2-13-01<br>2-22-69 | Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84365) 2-32-43 2-32-52 2-32-50 2-32-53 | Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84375) 2-38-07<br>2-31-52<br>2-30-07 | Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85557) 7-84-66 7-86-91 | Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85558) 7-10-64<br>7-09-76<br>3-26-89 | Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодольск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84371) 5-58-80<br>5-77-54<br>4-16-62 | Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84370) 2-11-12 2-15-57 | Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84377) 2-15-57 2-12-69 | Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84364) 2-84-76 2-64-65 | Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84378) 2-49-70 | Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85595) 5-07-51<br>6-02-26<br>5-50-03 | Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85563) 3-12-36 3-12-64 | Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеевск муниципаль | (85549) 2-23-00 2- | Usz.Mendeleev@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | 04-53 | |
| Минзәлә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85555) 3-26-59 | Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85556) 2-57-37 2-57-69 | Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8552) 53-60-33 | Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районы социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8555) 45-39-20 45-43-86 45-43-89 45-35-02 | Usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84348) 2-20-15 2-27-91 | Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84345) 2-06-62 2-06-81 2-39-88 | Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84367) 3-06-68 3-06-72 3-00-15 | Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84361) 2-11-57 2-39-62 | Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84362) 2-28-11 2-28-55 | Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85559) 2-45-72 2-44-37 | Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84347) 3-00-00 3-08-98 | Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84373) 2-62-31 | Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районының социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (8552) 70-00-57 70-13-41 | Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84360) 2-18-56 | Usz.Tulachi@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Чирмешән муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84396) 2-57-05 2-29-38 | Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84342) 5-55-73 5-12-06 | Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85593) 2-60-41 | Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәренең Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 571-58-00 570-06-31 | Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан шәһәренең Вахитов районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 238-10-55 238-41-91 | Osz.Priv@tatar.ru |
| Киров, Мәскәү районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 554-47-80 554-74-57 554-22-75 | Usz.Kirov@tatar.ru |
| Казан шәһәренең Яңа Савин районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 523-75-82 523-73-20 | Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан шәһәренең Идел буе районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 273-18-06 | Msz.SovOR@tatar.ru |

## 5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазифа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | (843) 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-14 | Yuliya.Abdreeva@tatar.ru |
| Социальхезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге башлыгы | 557-20-53 | Almaz.Abdullin@tatar.ru |
| Социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге башлыгы | 557-20-57 | Anzhelika.Valeeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге җитәкчесе | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

## 6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазифа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | (843) 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |